Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

10.03.2022 ел Менделеевск ш. №157

Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм (яисә) яңадан планлаштыру һәм күпфатирлы йортта урыннарны яңадан үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тәкъдимнәренә таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1.Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 550 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру турында актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының 2 бүлегенең 2.5 пункты 2.5.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) газлаштырылган күпфатирлы йортларда биналарны яңадан планлаштыру һәм (яисә) яңадан урнаштыру эшләрен газ бүлүче оешма белән килештерү.».

2. Район Советының мәгълүмати технологияләре белән тәэмин итү бүлегенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән административ регламентны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.И.Беляев